Эшне үтәде: Казан шәһәре 16 нче татар-инглиз гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мортазина Алия Фоат кызы.

Тема:Сүз басымы.
Максат: Иҗек турында белемнәрне барлау, сүз басымын дөрес билгеләү һәм дөрес кулланырга өйрәтү, сөйләмдә сүз басымының дөрес кулланылышын күзәтү, туган телгә мәхәббәт тәрбияләү.
Дәрес тибы; Яңа материал үзләштерү.
Җиһазлау: Дәреслек, "Татар теле” Ф.Ф. Харисов, Ч. М. Харисова, Слайдлар белән эшләү.
Дәрес барышы.
I.Мотивлаштыру- ориентлашу
1) Уңай психологик халәт тудыру;
-Укытучы: Укучылар , сез узган дәрестә иҗек турында белем тупладыгыз. Әйдәгез әле, нәрсәләр исегездә калды икән, тикшереп китик.
-Ягез әле, үткәннәрне кабатлау йөзеннән әйтеп үтегез, фонетика булеге нәрсә өйрәнә?
-Орфоэпия нәрсә өйрәнә?
- Татар алфавитында ничә хәреф бар? (авазлар турында белгәннәрне гомумиләштерергә һәм системага салырга мөмкинлек туа)
- Укучылар әйтегез әле, сүзләр нәрсәләрдән тора? Иҗек дип нәрсәгә әйтәбез? (сүзләр иҗекләрдән тора, иҗек – сөйләмнең иң кечкенә әйтелү берәмлеге. Сузык аваз иҗекнең үзәген тәшкил итә. Сүздәге иҗекләр саны сузык авазларга бәйле)
-Ачык һәм ябык иҗекләрне беләсезме сез? (Иҗекләр бер, яки берничә аваздан торырга мөмкин. Ачык иҗек сузык авазга, ябык иҗек тартык авазга тәмамлана: ә-ни (С-ТС), бал (ТСТ)).
-Әйе, бик дөрес. Сез үткән материалны дөрес үзләштергәнсез, афәрин. Буген без, сезнең белән яңа бер тема үтербез. Ләкин, аңа хәтле сезнең өй эшләрегезне тикшереп утик.
2) Өй эшләрен тикшерү.
-Ягез әле, өй эшенә нәрсә бирелде сезгә? (“Казан- Татарстанның гүзәл җире” темасына 10 җөмләдән торган сочинение язып килергә)
-Бик яхшы сочинение, афәрин.
-Ягез, тагын бер укычыны тыңлап үтик.
-Бик яхшы сочинение, афәрин. Өй эшләрегезне җиренә җиткереп утәгәнсез, инде миңа әйтеп үтегез, өй эшләрен үзегез генә башкардыгызмы, әллә әти-әниләрегез дә булыштылармы? Сезнең сочинениеләрегез миңа бик ошады. Рәхәтләнеп тыңладым үзегезне. Игътибар иттегезме, сез бөтен сүзләрне дә дөрес итеп укыдыгыз. Ничек уйлыйсыз? Нинди очракларда сузләдә мәгънә югалырга мөмкин? Әлбәттә, сузнең басымын дөрес түгел итеп куеп сөйләшкән очракта. Без дә сезнең белән буген сүз басымы темасын өйрәнеп китербез. Дәрес башында тыңлап үткән “Ай былбылым” җыры мисалында без сезнең белән басымны дөрес куюның кирәклеген карап үтәрбез.

Укучылар, әйдәгез шушы татар халкының иң матур булган җәүһәрләренән берсе булган җырыбызны бергә басып, матур кул хәрәкәтләре белән җырлап китик. Үзебезнең бай мирасыбызны, телебезне, җырларыбызны, гореф-гадәтләребезне онытмыйк! Халык җырларында уткәнебез, тарихыбыз ярылып ята. Үткәнне белмәсәк, әлбәттә, бәхетле киләчәк булмас!
*Физкультминут. (Җырлап бию.Музыкасыз). Афәрин, матур итеп ял да итеп алдык. Ә хэзер инде мин сезгә басым дөрес куелмаган очракны җырлап күрсәтим, Рәхим итеп тыңлагыз. (Укытучы җырлый). Ягез, кем миңа әйтеп бирә, басым үзгәргәч нәрсә үзгәрде? (Сүзнең мәгънәсе, көй, фикеребез үзгәрә). Моң дигән төшенчә ул безнең татар телендә генә бар. Ә газиз ана, татар телебез аркылы без сөйләшеп аралашабыз. Телебез белән горурланабыз, аны киләчәк буынга зәгыйфләндермичә җиткерү өчен яратып өйрәнәбез, саклыйбыз. Башка телләрне дә үзләштереп, төрле милләт вәкилләре белән дә дус яшәргә омтылабыз.
II.Яңа теманы аңлату. (7-8-9 нчы слайдлар, 3 кагыйдә үзләштерү, тактада дөрес булган рәтне тикшерү.1-а,2- а ).
Укытучы. Дөрес, димәк басым дөрес куелыу очракларын үзләштердек. Ә хәзер әйдәгез, дәреслектәге 121 нче күнегүнең биремен карыйк. Ни эшләргә кирәклеген аңлатып бирегез эле миңа. (Укып аңлаталар).
-Укучылар, димәк, без бүген басым турында сөйләшербез.
Дәфтәргә число, тема, сыйныф эше, күнегү номеры языла.
III.Белемнәрне ныгыту.
(Тактада беренче 5 җөмләне 5 укучы эшли, калганнар 6 нчы сүздән соңгы сүзләрне урыннарда эшли һәм эшләп бетергәч, партадашлар бер-берләренең эшләрен тикшерәләр).
Бирелгән сүзләрдә басымны билгеләргә. Дәрескә УМ куярга.
Көтелгән җавап: матур, икмәк, суда, буран, килә.
IV.Алма ярьдәмендә ныгыту эше. Карточкалар белән эш.
- Ягез эле балалар, минем кулымдагы алманы күрәсезме? (Күрәбез). Бу алма гади генә алма түгел, алмадагы телемнәрдән сүзләр чыгарып, шул сүзләрне укып сезнең белән дөрес басым куярга тиешбез.
Андый, укы, кызым, дәрес, былбыл.
Сүз басымын билгеләргә.(бергәләп тикшерү)
V.Йомгаклау.
Укучылар. димәк без бүген басымны карадык.Сезнең нәрсәләр исегездә калды?
-Сүз басымы дип нәрсәгә әйтәләр? (Ике яки берничә иҗекле сүздә көчлерәк әйтелгән иҗек басымлы иҗек дип атала).
-Татар телендә басым гадәттә, кайсы иҗеккә төшә? (Татар телендә басым соңгы иҗеккә төшә).
VI. Укучыларга билгеләр кую.
Бүгенге дәрестә барыгыз да актив катнаштыгыз, барыгызга да “5” ле билгеләре куям. Дәресебезне тәмамлап, өйгә эш язып алыйк укучылар.
VII. Өй эше. Аңлатып бирү.

А) 63 биттэге кагыйдәне өйрәнергә;
Б) 64 нче бит 122 нче күнегү (язмача).